**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «08» апреленнән № 93

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2020 елның 11декабрендәге 323 номерлы карары белән расланган «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2020 елның 11декабрендәге 323 номерлы карары белән расланган «2021 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Программасын финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» 2025 елга республика бюджеты бүлегендә «144,0» санын «75,86» санына алмаштырырга;

«Программаны финанс белән тәэмин итү» турындагы 6 пунктның

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең матди – техник базасын ныгыту» турындагы 1 пунктчасында 2025 елга «144,0» санын «75,86» санына алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 11 декабрендәге 323 номерлы карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль максатчан программасына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 11 мартындагы 101 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов